**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 6 июне** **№ 54**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 26 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» нигезендә 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр,

чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 26 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), хисап чорында цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сөйки авыл җирлеге башлыгы В.П.Никитинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Сөйки авыл
җирлеге башлыгы, Кама Тамагы муниципаль
районының Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе: В.П. Никитин